ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
4379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2019 елның 9 | № 112

д. им. М. Вахитова

**Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 6 ноябрендәге 1нче, 2нче номерлы, 2019 елның 1 декабрендәге 3нче номерлы, 2019 елның 8 декабрендәге 4нче номерлы гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирде:

1. Югары Ослан муниципаль районы Вахит авыл җирлегендә гражданнарның узара салым акчасын  җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Вахитов  авыл җирлеге башлыгы** **Кәримов Ф. Р.**

Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 9 декабреннән
112 номерлы карарына
1нче кушымта

**Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 мартына кадәр Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегендә гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү белән (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашыруга яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр https://uslugi.tatarstan.ru/ порталы ссылкасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 9 декабреннән
112 номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И. О.
________________________________________________________________________

Адресы: ________________________________________________________________

Сезгә ______________________________________нигезендә ___________________

вакытында кадәр ________________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр ________________ сум түбәндәге реквизитлар буенча__________________________________________ түләргә кирәк.

Алучының банк БИК _____________________________

Сч. № ______________________________

Алучының сч. № ___________________________________

ИНН ___________________________________

КПП ___________________________________

КБК ________________ ОКАТО_____________

Түләү билгеләү
_____________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________

(имза) (имзаны роасшифровкалау)

М. у.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
_______________________________________________________________________

(муниципаль берәмлек исеме)

бюджетына үзара салым буенча ________________ суммада бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И.О. __________________________________

Адресы: ________________________________________________________________

Алган «__» _______________ 20__ ел__________________

( түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Аермалы кәгазь тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылса ______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала .*